| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>БУА ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА<br>КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 06 » сентябрь 2024 ел Буа шәһәре № 48

Буа шәһәре территориясендә йорт
хайваннарының йөрү урыннарын
билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Буа шәһәре» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 14 ноябрендәге 3-27 номерлы Буа шәһәр Советы карары нигезендә, шулай ук санитария кагыйдәләрен һәм Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре территориясендә гигиена нормативлары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Буа шәһәре Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Өрәңгеле урамында, Б.Хмельницкий урамындагы 33 нче йорт янында урнашкан җир кишәрлеген йорт хайваннары йөрү урыны итеп билгеләргә.
2. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә Буа муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Җитәкче А.М.Сафин